СОВЕТ СВИЯЖСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
СВИЯЖСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тел/факс: (84371) 3-89-00, E-mail:Svg.Zel@tatar.ru, Сайт https://zelenodolsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«14» апрель 2026 елның а. Свияжск(Зөя) №35

Свияжск авыл җирлеге Советының 2021 елномерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжск авыл җирлеге советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Свияжск авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 августындагы №41, 2021 елның 12 декабрендәге №55, 2023 елның 16 мартындагы №107, 2023 елның 09 августындагы №125 карары белән)

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы №33-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Зеленодольск муниципаль районының Свияжск авыл җирлеге советы карар кылды:

1. 2021 елның 04 мартындагы №27 номерлы Свияжск авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжск авыл җирлеге советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә (Свияжск авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 августындагы №41, 2021 елның 12 декабрендәге №55, 2023 елның 16 мартындагы №107, 2023 елның 09 августындагы №125 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районы Татарстан Республикасы Свияжск авыл җирлегенең мәгълүмат

стендларында: Свияжск авылы, Троицкая ур., 7 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Успенская ур., 2 йорт («Буян» кибетенә кергәндә) адреслары буенча урнаштырырга.

Свияжск авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе М.Г. Ганеев